**Класс: 7**

**Укытучы:Исмагилова Гүзәл Дамировна**

**Программа: Ю.Н. Макарычев, Н.Г. Миндюк**

**Тема: Нәрсә ул функция?**

**Максаты:**

**– зурлыклар арасындагы бәйлелекне тикшерү;**
**– Функцияне бирү ысулларын өйрәнү.**
**Планлаштырылган нәтиҗә:**

**– Укучыларда функция төшенчәсен һәм функциянең тиңдәшле кыйммәтләрен табу күнекмәләрен формалаштыру.**

**(слайд 2)Исәнмесез, укучылар!** Гади тормышта без гел нindидер зурлыклар белән очрашабыз: температура, бәя, озынлык, предметлар саны, мәйдан, күләм һ.б. Шул вакытта, нindидер очракта бер зурлыклар үзгәрәләр, ә калганнары үзгәрешсез калалар.

**(слайд 3)**Төрле кыйммәтләр алган зурлыкның үзгәрешле зурлык дип аталганын без инде беләбез. Мәсәлән, сез автобуста берничә тукталыш үттегез ди. Ул вакытта автобусның тизлеге, бактагы бензинның күләме, пассажирлар саны – үзгәреп торалар, шуңа күрә алар үзгәрешле зурлыклар булырлар. Ә автобусның тәгәрмәчләр саны һәм тәрәзәләр саны юл йорү вакытында үзгәрми, шуңа күрә алар даими зурлык булырлар.

**(слайд 4)**Мәсәлән, 50 м/мин тизлек белән барган юлның озынлыгы сезнең күпме вакыт йөрүгезгә бәйле.

**(слайд 5)**Өстәвенә үткән юл сайлап алынган вакыт белән төгәл билгеләнә: 5 минутта сез 250 м, 12 минутта – 600 м, 20 минутта – 1000 м үтәчәксез.

$$v = 50 \text{ м/мин}$$

| $t$ | 5 мин | 12 мин | 20 мин |
|---|---|---|---|
| $S$ | 250 м | 600 м | 1000 м |

**(слайд 6)**50 м/мин тизлек белән бирелгән $t$ мин вакыт эчендә үткән юлны $S$ м без ничек билгеләдек? Без $t$ минутның берничә төгәл кыйммәтен алдык (5 мин, 12 мин, 20 мин һ.б.), аннары, $S = 50t$ кагыйдәсен кулланып, $t$ минутны 50 м/мин ка тапкырлап эзләнелгән $S$ м кыйммәтен таптык. (250 м, 600 м, 1000 м һ.б).

**(слайд 7)**$t$ үзгәрешлесенең мөмкин булган кыйммәтләре нindидер $T$ күплеген хасил итә. Шул ук очракта $t$ теләсә нинди кыйммәтләр ала алмый. Ягъни җәяү йөрү 1000 000 мин яки (-24) мин ка сузалы алмый.

**(слайд 8)**Әгәр дә инде ул, мәсәлән, 30 мин ка сузылса, $T$ күплеген алдагы рәвештә бирергә мөмкин: $T = \{0 \leq t \leq 30\}$. $s$ (метрларда) үзгәрешлесе кыйммәтләрне бу очракта ниндидер $S$ күплегеннән ала: $S = \{0 \leq s \leq 1500\}$

**(слайд 9)**Биредә $S = 50t$кагыйдәсе буенча, $T$ күплегеннән һәр $t$ элементына тиңдәшле рәвештә $S$ күплегеннән бер элемент куелды.

Димәк без Т күплеге белән $S$ күплеге арасында бәйләнеш урнаштырдык. Мондый бәйләнеш *функциональ бәйләнеш* яки *функция* дип атала.

**(слайд 10)**Ике үзгәрешле арасындагы бәйлелек функция дип атала. Т күплегенең элементларын *бәйсез* үзгәрешле дип, ә $S$ күплегенең элементларын *бәйле* үзгәрешле дип атыйлар.

**(слайд 11)**Бер үзгәрешленең икенчесенә бәйлелеге һәрвакытта да функция булмый. Мәсәлән, автобус маршрутының озынлыгы 15 км булсын. Юл бәясе түбәндәге таблица белән билгеләнә:

| | | |
|---|---|---|
| 20 сум | 40 сум | 60 сум |
| 5 км га кадәр | $5 - 10$ км | $10 - 15$ км |

**(слайд 12)**Бу таблицадан күренә 1 км га да 20 сум, 2,3,4,5 км га да 20 сум туры килә. Ягъни, үзгәрешле билет бәясенең бер кыйммәтенә икенче үзгәрешле юл озынлыгының берничә кыйммәте туры килә. Бу бәйлелек функция түгел.

**(слайд 13)***Билгеләмә. бәйсез үзгәрешленең һәр кыйммәтенә бәйле үзгәрешленең бердәнбер кыйммәте туры килә торган бәйлелек функциональ бәйлелек яки функция дип атала.*

Гадәттә, бәйсез үзгәрешлене $x$ дип, ә бәйле үзгәрешлене $y$ дип билгелиләр. Бәйсез үзгәрешлене икенче төрле *аргумент* дип атыйлар, ә бәйле үзгәрешлене шул аргументка бәйле *функция* диләр. Бәйле үзгәрешленең кыйммәтләрен функциянең кыйммәтләре дип атыйлар.

Бәйсез үзгәрешле кабул иткән барлык кыйммәтләр функциянең билгеләнү өлкәсен төзиләр.

$X$ күплегенә кергән кыйммәтләр функциянең билгеләнү өлкәсе дип, ә $Y$ күплеге кыйммәтләр өлкәсе дип атала.

**(слайд 14)** Мәсәлән, $y = x(x + 5)$; $y = \frac{x-3}{5}$ формулалары белән бирелгән функцияләрнең билгеләнү өлкәсе барлык саннардан тора, ә $y = \frac{1}{x-2}$ формуласы белән бирелгән функциянең билгеләнү өлкәсе, 2 саныннан кала, барлык саннардан тора.

**(слайд 15)** Ә хәзер функцияне бирү ысулларын карыйк. Функцияне берничә ысул белән бирергә була.

1. Җөмләләр ярдәмендә бирү.

Мәсәлән, квадратның мәйданы анын ягының озынлыгына бәйле;

Билгеле бер тизлек белән барган юлның озынлыгы вакытка бәйле

**(слайд 16)** 2. Күплекләр ядәмендә бирү.

**(слайд 17)** 3. Таблица ярдәмендә бирү.

**(слайд 18)** 4. Формула ярдәмендә бирү. Формула ярдәмендә бирүне икенче төрле аналитик ысул диләр.

**(слайд 19)** Димәк, без функция бирүнең 4 ысулын карадык:

1. Җөмләләр ярдәмендә бирү.
2. Күплекләр ядәмендә бирү.
3. Таблица ярдәмендә бирү.
4. Формула ярдәмендә бирү.

Функцияне бирүнең тагын бер ысулы бар – график юл ярдәмендә бирү. Бу ысулны без алдагы дәрестә карап үтәрбез.

**(слайд 20)** Әлегә практик биремнәргә күчик.

1 бирем. $X$ һәм $Y$ күплекләре арасындагы бәйләнеш алдагы схема белән бирелгән. Кайсы бәйләнеш функция булыр?

Функция төшенчәсе аңлатмасыннан без күрәбез: а һәм г схемаларындагы бәйләнеш функциональ, ә б һәм в схемаларындагы бәйләнеш функциональ түгел. Чынлап та, а һәм г очрагында Х күплегеннән һәр элементы өчен У күплегеннән тиңдәшле элемент бар һәм ул бердәнбер. Б очрагында Х күплегеннән 3 саны өчен У күплегеннән бер элемент та тиңдәш итеп куелмаган. Ә в очрагында  Х күплегеннән 3 саны өчен У күплегеннән берьюлы ике элемент та тиңдәш итеп куелган (6 һәм 7 саннары) . ( ягъни тиңдәшле элементның бердәнберлек таләбе үтәлмәгән).

**(слайд 21)** 2 бирем. Тигезьяклы өчпочмакның периметры белән аның ягы үзара бәйлеме? Әгәр өчпочмакның ягы $a$га тигез, ә периметры – $P$ булса, $P$ үзгәрешлесенең $a$ үзгәрешлесеннән бәйлелеген нинди формула белән бирергә мөмкин? Бу бәйлелек функциональ булырмы?

Җавап: Өчпочмак тигезьяклы булгач, димәк, аның бар яклары да тигез. Периметрны табу өчен без өчпочмакның барлык якларын да кушабыз: $P = a + a + a = 3a$. Димәк,  $P$ үзгәрешлесенең $a$ үзгәрешлесеннән бәйлелеген $P = 3a$ формуласы белән бирергә була. Бу бәйлелек функция.

**(слайд 22)** 3 бирем. Кубның күләме $V$ белән аның кабыргасы $a$ озынлыгы арасындагы бәйләнешне бирегез. Әлеге бәйләнеш функция булырмы?

Җавап : $V = a^3$. Әлеге бәйләнеш функция.

**(слайд 23)** 4 бирем. Яклары 8 см һәм $x$  см булган турыпочмаклыкның мәйданы  $S$ см$^2$. $S$ ның $x$ ка бәйлелеген формула ярдәмендә күрсәтегез. Аргументның кыйммәтләре $x = 2; 4, 5; 6$  булганда функциясенең тиңдәшле кыйммәтләрен табыгыз.

$$S = 8 \cdot x$$

$$x = 2 \rightarrow 8 \cdot 2 = 16;$$

$$x = 4,5 \rightarrow 8 \cdot 4,5 = 36;$$

$$x = 6 \rightarrow 8 \cdot 6 = 48;$$

**(слайд 24)** 5 бирем. Функция $y = 10x + 1$ формуласы белән бирелсен, биредә $-2 \leq x \leq 2$. $x$ ның бөтен сан кыйммәтләренә тиңдәшле $y$ кыйммәтләрен табарга.

әгәр $x = -2$ булса, $y = 10 \cdot (-2) + 1 = -19$;

әгәр $x = -1$ булса, $y = 10 \cdot (-1) + 1 = -9$; һ.б.

Өстәге юлга - аргумент кыйммәтләрен, астагы юлга функциянең тиңдәшле кыйммәтләрен урнаштырып, исәпләү нәтиҗәләрен таблица рәвешендә язу уңайлы:

| $x$ | $-2$ | $-1$ | $0$ | $1$ | $2$ |
|---|---|---|---|---|---|
| $y$ | $-19$ | $-9$ | $1$ | $11$ | $21$ |

Без $x$ ның кыйммәтен адым саен 1 гә арттыра барып сайладык. Мондый очракта функциянең кыйммәтләре таблицасы 1 адымы белән төзелгән, диләр.

Каралган мисалда функциянең билгеләнү өлкәсе күрсәтелгән иде.

**(слайд 25)** 6 бирем. Функция $y = 5x + 2$ формуласы белән бирелгән. $x$ ның нинди кыйммәте өчен функциянең кыйммәте 12 гә тигез икәнен табарга.

Функциянең кыйммәте 12 гә тигез булгач, $y = 5x + 2$ формуласында $y$ урынына 12 санын куйыйк. $x$ үзгәрешлесе кергән тигезләмә табарбыз:

$$12 = 5x + 2$$

Аны чишеп табабыз: $x = 2$.

Димәк, $x = 2$ булганда, $y = 12$.

Шуны искәртәбез: мәсьәлә чишү ысулы безгә таныш булган тигезләмәгә китерелде, шуңа күрә без аны чишә алдык.